# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. **Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен төзү, аларның эшчәнлеген оештыру һәм аларны бетерү, Татарстан Республикасы коткаручылары эшчәнлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен төзү, аларның эшчәнлеген оештыру һәм аларны бетерү, Татарстан Республикасы коткаручылары эшчәнлеге өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә һәлакәттән коткару хезмәтләрен, һәлакәттән коткару формированиеләрен төзү, аларның эшчәнлеген оештыру һәм аларны бетерү һәм коткаручылар эшчәнлеге мәсьәләләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итә ала.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 5 июле
№ 53-ТРЗ